ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 519-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 519-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2400-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

### 1 статья

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 4, № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә барлыкка килгән документлар – Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын кулланып, дәүләт ярдәме чаралары сыйфатында һәм аларны бирү процессында барлыкка килгән документлар. Документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

2) 7 статьяның өченче өлешендә «һәм проектлау документларының» сүзләрен «, проектлау документларының һәм дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә барлыкка килгән документларның» сүзләренә алмаштырырга.

### 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Башлыгы (Рәисе)

**«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасының әлеге закон проекты, аларны архив фондына кертүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына керүче документларның төрләрен киңәйтү зарурлыгына бәйле рәвештә эшләнде.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең 20дән артык башкарма органы дәүләт ярдәме чараларын (юридик һәм физик затлар өчен грантлар һәм субсидияләр рәвешендә) гамәлгә ашыра.

Аларның бер өлешен гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, шулай ук мондый чараларны бирү процессында документлар барлыкка килә.

«Россия Федерациясендә Архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Архив фонды составына аларның барлыкка килү чыганагына, барлыкка килү вакытына һәм ысулына, күчергеч төренә, милек рәвешенә һәм саклау урынына бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе территориясендә урнашкан архив документлары, шул исәптән юридик актлар, идарә документлары, фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләре булган документлар, шәһәр төзелеше документлары, кино-, фото-, видео - һәм фонодокументлар, электрон һәм телеметрик документлар, кульъязмалар, рәсемнәр, сызымнар, көндәлекләр, хатлар, мемуарлар, төп нөсхәләр хокукында архив документлары күчермәләре, шулай ук чит ил дәүләтләрендәге дәүләт оешмаларының архив документлары керә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт ярдәме чаралары буларак бирелгән акчаларны кулланып ясалган, шулай ук мондый чараларны бирү процессында барлыкка килгән һәм Федераль законда күрсәтелгән документларга караган документлар Татарстан Республикасы Архив фондына кертелергә һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ (алга таба – Дәүләт архивына) саклауга тапшырылырга тиеш.

Шуның белән бергә, архив документларын дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Дәүләт архивына саклауга тапшыруның архив эше өлкәсендә законнар белән билгеләнгән схемасын куллану (даими саклау вакытлы документларны тапшыруны һәм эш башкару тәмамланганнан соң 10 ел узгач документларны тапшыруны күздә тота) дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру барышында барлыкка килгән документларның сакланышы һәм алардан файдалануның барлык максатларына җавап бирми.

Беренчедән, башкарма хакимият органнарының күпчелек өлешендә әлеге документлар аның нигезендә Дәүләт архивына даими саклауга документлар сайлап алына торган эш номенклатурасына кертелми.

Икенчедән, формалаштырылган эшләрнең бер өлеше вакытлыча саклауга гына ия.

Өченчедән, документларны Дәүләт архивына саклауга тапшырганда, эш башкару эшләре тәмамланганнан соң 10 ел узу белән, әлеге документларның тапшыру вакытына гамәли ихтыяҗы һәм актуальлеге кимиячәк.

Документларның тиешле категорияләрен Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсенә кертү күрсәтелгән проблеманы хәл итү юлы булып торачак. «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 2 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъектының мәҗбүри экземпляры составына керүче документларның төрләрен үз ихтыяҗларын исәпкә алып билгели ала.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, закон проекты белән Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт ярдәме чаралары буларак бирелгән акчаларны кулланып ясалган, шулай ук мондый чараларны бирү процессында барлыкка килгән документларны Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе составына кертергә тәкъдим ителә. Билгеләнгәннәр арасыннан булган, мәҗбүри экземплярга керә торган документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнәчәк.

Тәкъдим ителгән үзгәрешләр дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә барлыкка килгән документларны, аларны саклап калу һәм кызыксынган дәүләт органнары һәм оешмалар тарафыннан алга таба файдалану максатыннан, архив фонды составына оператив һәм тулы күләмдә кертергә мөмкинлек бирәчәк һәм бюджет акчаларын нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итәчәк.

**«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме чаралары күрсәткәндә барлыкка килгән, Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсенә керә торган документлар исемлеген раславы, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча фәнни-проект документларының һәм проект документларының мәҗбүри нөсхәсен алып килеп бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 декабрендәге 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

Әлеге эшчәнлек «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУ дәүләт биреме кысаларында башкарылачак, шул ук вакытта дәүләт заданиесенең үтәлешен финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру таләп ителми.